КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 декабрь г.Казань № 1216

Татарстан Республикасы Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Аэропорт - Столбище» - «Россия Почтасы» ФДУП Казан логистик почта үзәге» автомобиль юлын төзү максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Главтатдортранс) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Аэропорт - Столбище» - «Россия Почтасы» ФДУП Казан логистик почта үзәге» автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, «АК БАРС КАПИТАЛ» идарә компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәсендәге «АК БАРС – Горизонт» ябык пай инвестиция фондының инвестиция пайлары хуҗаларының (алга таба - җир кишәрлегенең милекчесе) өлешле милкендә булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең 16:24:150301:1064 кадастр санлы 7 653 624 кв. метр мәйданлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 4 604 кв. метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба - алына торган җир кишәрлеге) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән 16:24:150301:1064 кадастр санлы җир кишәрлегеннән төзелә торган 4 604 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең урнашу схемасын расларга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны бастырып чыгарырга;

әлеге карарның күчермәләрен Главтатдортрансdefinitely, җир кишәрлеге милекчесенә, «Росреестрның Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына җибәрергә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Главтатдортранс белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләргә һәм аны җир кишәрлеге хуҗасына җибәрергә;

килешү төзергә;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләргә;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәвенә алырга;

җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан закон белән билгеләнгән срокта кул куелган килешү тапшырылмаган очракта судка тиешле дәгъвалар бирергә.

4. Бу карарның 2 пункты белән расланган 16:24:150301:1064 кадастр санлы җир кишәрлегеннән төзелә торган 4 604 кв. метр мәйданлы җир кишәрлегенең урнашу схемасына ярашлы рәвештә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрүне Главтатдортранска тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.


Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 29 октябрь, 1216 нчы
карары белән расланды

16:24:150301:1064 кадастр санлы җир кишәрлегеннән төзелә торган 4 604 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең урнашу схемасы

| Җир кишәрлегенең шартлы номеры – :1064:ЗУ1 | | |
|---|---|---|
| Җир кишәрлегенең мәйданы 4 604 кв.метр | | |
| Координаталар системасы: МСК-16 | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координаталар, метр | |
| | Х | У |
| (1) | | |
| н1 | 458076.29 | 1313585.56 |
| н2 | 458084.59 | 1313607.88 |
| н3 | 458060.80 | 1313583.05 |
| н4 | 458060.18 | 1313577.95 |
| н5 | 458069.82 | 1313574.92 |
| н1 | 458076.29 | 1313585.56 |
| (2) | | |
| н6 | 458187.38 | 1313522.82 |
| н7 | 458235.51 | 1313725.00 |
| н8 | 458229.35 | 1313718.52 |
| н9 | 458215.78 | 1313681.51 |
| н10 | 458207.12 | 1313643.54 |
| н11 | 458191.16 | 1313639.39 |
| н12 | 458190.49 | 1313636.26 |
| н13 | 458152.59 | 1313642.58 |
| н14 | 458124.84 | 1313649.89 |
| н15 | 458102.65 | 1313626.73 |
| н16 | 458117.42 | 1313622.81 |
| н17 | 458144.18 | 1313617.57 |
| н18 | 458183.17 | 1313605.24 |
| н19 | 458182.29 | 1313602.00 |
| н20 | 458195.57 | 1313592.89 |
| н21 | 458188.82 | 1313560.04 |
| н22 | 458185.31 | 1313540.23 |
| н23 | 458183.25 | 1313523.73 |
| н6 | 458187.38 | 1313522.82 |

# Җир кишәрлеге чикләрен күзәтү схемасы





Масштаб 1:25 000

Шартлы билгеләмәләр:

| | |
|---|---|
| 16:24:150301:1064 | - беренчел җир кишәрлегенең кадастр саны; |
| :1064:ЗУ1 | – төзелә торган җир кишәрлеген билгеләү; |
| 16:24:150301 | - кадастр кварталын билгеләү; |
| (red rectangle) | - яңа төзелгән чикнең бер өлеше, аның урнашу урынын билгеләү өчен аның турында мәгълүматлар җитәрлек; |
| н1 | – икнең характерлы ноктасын билгеләү, аның урнашу урынын билгеләү өчен аның турында мәгълүматлар җитәрлек; |
| (black line) | – җир кишәрлекләре чиге; |
| (blue line) | - кадастр кварталы чикләрен билгеләү; |
| (hatched rectangle) | - территорияләрне кулланунын аерым шартлары булган зоналар чикләрен билгеләү. |

1 бит




Масштаб 1:2000

Шартлы билгеләмәләр:

16:24:150301:1064 - беренчел җир кишәрлегенең кадастр саны;

:1064:ЗУ1 – төзелә торган җир кишәрлеген билгеләү;

16:24:150301 - кадастр кварталын билгеләү;

- яңа төзелгән чикнең бер өлеше, аның урнашу урынын билгеләү өчен аның турында мәгълүматлар җитәрлек;

н1 – икнең характерлы ноктасын билгеләү, аның урнашу урынын билгеләү өчен аның турында мәгълүматлар җитәрлек;

– җир кишәрлекләре чиге;

- кадастр кварталы чикләрен билгеләү;

- территорияләрне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләрен билгеләү.